

***/Укучылар иҗаты/***

### *Айсылу маҗаралары*

Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди әби белән бабай. Аларның Айсылу исемле кызлары булган. Көннәрдән бер көнне әбисе кызын җиләк җыярга җибәргән. Чөнки бу җәйне аларның җиләк-җимешләре уңмаган, ди. Ерак йөрергә теләмичә, Айсылу якындагы урман эченә генә кергән һәм җиләк җыярга тотынган. Күп вакыт та үтмәгән, агачлар арасында ниндидер тавыш ишетелгән. Айсылу игътибар бирмәгәч, тавыш яңадан кабатланган. Кызга әбисе якын урманга кермәскә дип кисәткән иде, чөнки анда ниндидер куркыныч тавышлар гел кабатлана торган булган.

Менә агачлар арасыннан дию пәрие килеп чыккан. Айсылу куркуыннан бик кызу чаба башлаган. Дию пәрие тиз генә кызны эләктереп, үз оясына алып кереп киткән. Әбисенең сүзләрен исенә төшергәндә, соң шул инде: ул дию тозагында. Айсылу монда тагын үзе кебек дүрт кызны күргән. Елаудан туктатыр өчен мондагы балалар аны тынычландырырга тотынганнар. Шул арада бер шуграк малай хәйләгә керешкән. Тиз генә качып котылсам, сезне дә коткарырга тырышырмын диеп ышандырган. Тырыша торгач, шул кечкенә Инсаф чыгып качу бәхетенә ирешә. Барлык балалар бергәләшеп еларга, төрле тавышлар чыгарырга тотынганнар. Бу тавышка Дию үзе килеп кергән, шул арада Инсаф ачкычларын алып качырга өлгергән. Дию малайның югалганын белеп, аның артыннан чапкан. Тик ул шунда гына качкан булып, барлык тоткыннарны ачып чыгара. Алар бергәләшеп урманга чыгып качалар. Дию артларыннан куып тотканчы, аучылар янына барып чыгарга өлгергәннәр. Аучылар аларга ярдәмгә әзер булып, Дию пәриеннән дә якларга тотынганнар. Шулай итеп, батыр аучылар балаларны гаиләләренә кайтарганнар.

Дию пәрие тозагына эләккәннәр - бөтенесе дә әти-әниләренең сүзен тыңламаган балалар булганнар. Чөнки аларның һәрберсен әбиләре дә, әниләре дә урман тирәсендә йөрмәскә кушкан булганнар. Белмәгән урында йөрүнең дә, сүзне тыңламауның да нәтиҗәсе куркыныч икәнен аңлаганнар.

***Кәүсәр Насыйрова, IV сыйныф укучысы***




***/Безнең спорт/***

Мәктәбебезнең яшь шахматчысы **Фаил Гафиятуллин** янәдән **Бөтенроссия шахмат турнирының призеры** булды. Ел саен иң көчле интеллектуаль спортчылар арасында уздырыла торган әлеге традицион турнир 19-23 гыйнвар көннәрендә Удмурт Республикасы Дебёсы районы үзәгендә үтте. Турнирда Россиянең 17 төбәгеннән авыл җирлегендә яшәүче 263 шахматчысын катнашты. Бәйге барышында 144 медаль өчен барлыгы 2500 партия уйналды. Беренче һәм дүртенче көнне партияләрнең онлайн трансляциясе алып барылды. Фаил 2 төркемдә призлы урыннар яулады: блиц буенча малайлар арасында III, блиц буенча 13 яшькә кадәр малайлар арасында II урынга лаек булды. Инде чемпионыбызга күз генә тимәсен диган теләктә калыйк.

Узган айда көрәш буенча бәйгеләр күп булмады. 27-28 нче гыйнвар көннәрендә Базарлы Матакта узган Республикакүләм билбау ярышында **Камалов Илдус** 2005-2007 нче елгы егетләр арасында, 60 кг авырлыкта III урынны алды.



***/Котлыйбыз!/***

Гыйнвар аенда дөньяга килгән укучыларыбыз **Залиев Ильфирны**, **Закирова Ләйсәнне, Хәбибрахманова Мәрьямне, Замалетдинова Инзиләне** һәм **Камалов Илдусны** чын күңелдән туган көннәре белән котлыйбыз. Укуыгызда уңышлар, сәламәтлек, тырышлык телибез. Барлык хыялларыгыз тормышка ашсын.

Хезмәттәшләребез **Зарипов Фәнил, Хөснуллин Фәнис абыйларны**, техник хезмәткәр **Сәгъдиева Рәмзия апаны**, балалар бакчасы кече тәрбиячесе **Баширова Альмира апаны** гомер бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлекнең ныгын, гомернең озынын телибез. Тынычлыкта, муллыкта яшәргә язсын.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева  Сара Насыйрова
Виктория Нукина  Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина

# Мәктәп хәбәрчесе

**№1**
**(№32)**
**гыйнвар**
**2022 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46**  **sch1644maina@mail.ru**

***/ Мөгаллим минбәре /***

### *Уен уйный беләбезме?*



Беркемгә дә сер түгел: хәзер без урамда уйнарга яратмыйбыз, күбрәк өйдә телефон тотып утырабыз. Безгә шундагы виртуаль дөньяда кызыграк. Күзләребез сукырая, гәүдәләребез кәкерәя, башларыбыз арый дип тә уйламыйбыз. Ә безнең әти-әни һәм әби-бабаларыбыз көннәр буе урамда саф һавада уйнаганнар. Шуңа күрә сәламәт тә, безгә караганда зиррәк тә булганнар. Нинди генә уеннар белмәгән алар! Аларның күбесе белән без хәтта таныш та түгел. Уеннарны таныган галимнәребез барлаган, җыйган, китап итеп тә бастырган. Шуңа да аларны халыкның бай хәзинәсе дип атап була. Уеннарга карап халыкның яшәү рәвешен, дөньяга карашын, мәдәни бизәкләрен өйрәнергә була.

Һәр ел фасылының үз уеннары бар. Кемгәдер җылы җәйдә су керергә, туп тибәргә, кемгәдер көзге урманда бай төсләрне санап йөрү дә ошый. Бәлки син җиргә тереклек иңгән язны көтәсеңдер. Гөрләвек җырына кушылып, итектән кар сулары кергәнче урамда йөрисеңдер. Кемдер сыкылы салкында да табигатьнең матурлыгына соклана белә. Чана-чаңгыда шуарга, кар атышып уйнарга, тәгәрәтеп Кар бабай ясарга була. Ә кар күп булса, уеннар тагын да кызыклырак. Быелгы кыш безгә кышкы уеннарның тәмен белеп калырга чакыра сыман. Өеп куйган көртләрдән выжылдап очып төшәсең, дә, тирләп-пешеп өскә үрмәлисең, аннан тагын, тагын. Бияләйләр боз булып катып, битләр уттай янса да, шундый рәхәт! Дусларың белән тимераякта шуарга да була. Боз өстенә беренче чыгу белән җиңел генә шуып китеп булмый, әлбәттә. Таеп китеп, бозга барып төшкән чаклар да күп булуы мөмкин. Тик сәламәт бала аннан гына куркып кала торганмыни?!

Уеннарның һәрберсе кызыклы һәм мавыктыргыч. Аларны уйнаганда вакыт узганы да сизелми. Җитезлекне, төгәллекне арттыралар, ә саф һавада уйналулары, хәрәкәтчән булулары белән сәламәтлекне ныгытуның иң ышанычлы чарасы булып торалар. Халкыбыз юкка гына "хәрәкәттә – бәрәкәт" димәгән. Шуның өстенә күмәк уеннар дуслыкны ныгыталар. Кагыйдәләре катлаулы булып тоелса да, бер-ике тапкыр уйнаганда истә калып бетәләр. Нәкъ менә катлаулырак булулары белән кызыктыралар да. Уенны ике кеше белән дә, зур команда белән дә уйнап була.

Татар халык уеннары халкыбызның тарихи гореф-гадәтләрен дә саклыйлар. Аларның кайберләрендә инде күптән кулланыштан төшкән сүзләр, җырлар, такмаклар була. Такмаклы уеннарның сөйләм теле үстерүдә дә әһәмияте зур. Уеннарның һәрберсенең барлыкка килү тарихы бар. Кайбер уеннар күп төбәкләргә таныш, ә кайберләрен бары тик аерым авылларда гына беләләр.

Без, замана балалары, хәрәкәтчән уеннарны бөтенләй уйнамыйбыз диярлек. Хәтта күбебез аларны белми дә. Шуңа күрә үзебезгә бурыч итеп куйыйк әле: яңа уеннар өйрәник, иптәшләребезне дә шуңа җәлеп итик. Бәлки, үзебезнең авылда гына билгеле булган уеннарны, әби-бабайлардан сорап, безгә тәкъдим итәрсез?

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

***/ Безнең уңышлар /***

### *Бакчага яңа уенчыклар кайтты*



Гәзитнең алдагы саннарында әйтеп үтелгәнчә, узган елда мәктәпнең бюджеттан тыш керемнәре исәбенә шактый күләмдә кирәкле җиһазлар алган идек. Инде менә бакчага йөрүче балаларны да шатландыру мөмкинлеге туды. Үткән елны төзегән 49 000 сумлык килешү буенча заказ биргән уенчыкларны алып кайттык. Алар арасында курчак, конструктор, машиналар кебек гадәти уенчыклар да, балаларны сәламәтләндерү өчен файдалы коры бассейн, гимнастика матасы, ортопедик пазллар да бар. Балаларны аеруча куандырганы 28 әре модульдән торган "Тезүче" конструкторы булды.

Әлеге товарлар Ярославль шәһәрендә җитештерелгәнлектән, аларны Казанга кайтару да шактый кыйммәткә төшәсе иде. Әлеге мәсьәләне хәл итәргә үзебезнең мәктәптә укып чыккан асыл егетләр – Ришат һәм Инсаф Гафиятуллиннар ярдәм итте. Аларга нәни балаларны шатландырган игелекле гамәлләре өчен барлык мәктәп коллективы исеменнән олы рәхмәтебезне белдерәбез!

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

**/Күренекле шәхесләр /**

## Әсгать абый бүләге



Үзенең туган җиренә тугры булган, гомер юлын авыл хуҗалыгына багышлаган шәхесләр турында күп ишеткәнебез бар. Шуларның берсе – авылыбызда гомер итүче Габдуллин Әсгать Касыйм улы. Әсгать абый 1966 нчы Түбән Майна авылында гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 1973-1981 нче елларда авылдагы сигезьеллык мәктәптә укый. Уку дәверендә тырыш һәм спорт сөючән укучы буларак танылa. Авыл мәктәбендә төп белем алганнан соң, укуын Иске Әдәм урта мәктәбендә дәвам итеп, 1983 нче елда аны да уңышлы тәмамлый. 1984-1986 нчы елларда данлыклы Байконур космодромында хәрби бурычын үти.

Армиядән кайтканнан соң Әсгать абый Казан авыл хуҗалыгы институтына агроном белгечлеге буенча укырга керә. 1991 нче елда институтны уңышлы тәмамлап, туган авылына эшкә кайта. Тормыш иптәше Гүзәлия апа да авылдагы “Уңыш” күмәк хуҗалыгына экономист булып эшкә урнаша. Әсгать абый башта колхозда гади механизатор булып эшли. 1993 нче елдан үзенең төп белгечлеге буенча агроном вазифасын үти башлый. Уңышлы эшләгәнен күреп, 1997 нче елда аны күрше Емелькино авылындагы “Восток” күмәк хуҗалыгына рәис итеп билгелиләр. Шул ук елның ахырында үзебезнең “Майна” күмәк хуҗалыгына җитәкче булып кайта.

Әсгать абый колхоз рәисе булып эшләгән еллар күмәк хуҗалыклар өчен бик киеренке чор буларак билгеле. Ул заманда тирә-яктагы бик күп колхозлрп банкротка чыгып ябылып бетәләр. Авырлыклар күп булуга карамастан, “Майна” күмәк хуҗалыгы Аксубай районында барлык күрсәткечләр буенча да алдынгы урыннарны биләп килә. Әсгать абыйның тырышлыгы белән 2003 нче елда авылга килә торган олы юлга асфальт салына башлый. Ул елларда безнең Түбән Майна авылы турында халык арасында соклануданмы, әллә көнләшепме, “Майна ул – дәүләт эчендәге дәүләт” дигән сүзләр йөри.

2004 нче елда Әсгать абый Аксубай районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы итеп алына. Шул чорда ул Казан авыл хуҗалыгы институтында аспирантура тәмамлап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты исеменә лаек була. 2005 нче елда Әсгать абый Түбән Майнада, моңарчы безнең якларда күрелмәгән яңа төр эш ачып җибәрә – теплицалар корып, кыяр үстерә башлый. Шулай итеп авылда яңа эш урыннары барлыкка килә. Мәрхүм этиләре Касыйм бабай да озак еллар дәвамында колхозның яшелчә бакчасы мөдире булып эшләгән. Яшелчәчелек эшен ярату Әсгать абыйга нәселдән дә күчкән булырга мөмкин.

2007-2014 нче елларда Әсгать абый “Кызыл Шәрыкъ - Агро” агрофирмасының Биләр филиалына җитәкчелек итә. Аннан соң, 2014-2018 елларда, Норлат шәһәре һәм районы башкарма комитет җитәкчесе булып эшли. Әйтергә кирәк, безнең авылдан чыккан кешеләр арасында соңгы 40 елда мондый зур административ вазифа биләүчеләр булмады. Норлаттагы хезмәт срогы тәгәлләнгәч, Әсгать абый “Аксубай” агрофирмасына генераль директор итеп куела, һәм бүгенге көндә дә шушы вазифаны башкара.

Әсгать абый, тормыш иптәше Гүзәлия апа белән өч бала тәрбияләп үстерделәр. Барча балалары да мәктәпнең иң алдынгы укучыларыннан булдылар. Уллары Азат белән Алмаз мәктәпне алтын медальгә тәмамладылар. Алмаз абый математика фәне буенча Бердәм дәүләт имтиханында 95 балл җыйган иде. Бу күрсәткечне Аксубай районында әлегә кадәр узучы булганы юк.

Бу кышны Әсгать абый безнең мәктәпкә кар чистарткыч бүләк итте. Быелгы кышның һава торышына күрә бу бүләк бик урынлы булып чыкты. Яхшылык җирдә ятмас ди, халык мәкале. Шушы олы ярдәме өчен Әсгать абыйга һәм аның гаиләсенә ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, җаваплы хезмәтенә уңышлар, һәм киләчәктә дә авылыбызны кайгыртып яшәүләрен теләп калабыз.


***Сара Насыйрова, XI сыйныф укучысы.***



**Яланаяклы балачак. 1975 нче елның җәе.**

**/Мәктәп тормышы/**

## "Пушкин картасы" чарасы – мәктәптә



Узган ел ахырында безнең мәктәптәге “Пушкин картасына” ия укучылар Аксубай үзәк китапханәсе тарафыннан әзерләнгән “Book – party” чарасына билетлар алган иделәр. Алдан килешенгәнчә, бу чараны үзәк китапханә хезмәткәрләре кышкы каникуллар тәгәлләнгәч мәктәпкә килеп уздырдылар.


“Book – party” чарасы ярыш формасында оештырылды. VIII-XI сыйныф укучылары 4 төркемгә бүленеп көч сынаштылар. Ярышка табышмаклар әйтү, заманча сүзләр белән яңалыкларны җиткерү, әкият геройларын табу кебек биремнәр кертелгән иде. Бу уеннар китап укучылар өчен чын мәгънәсендә сынау булды. Чөнки укылган әсәрләрнең геройларын искә төшереп, зирәклектә, тапкырлыкта көч сынаштык.

Ярыш ахырында лотерея уйнатылды. Төп приз кызыклы китап иде. Бүләкне 9 сыйныф укучысы Әхсәнов Халит отты. Ахырда китапханәче апалар укучыларга кечкенә генә бүләкләр өләштеләр. Мәктәпкә дә Татарстан тарихы буенча бик затлы китап бүләк ителде. Бәйрәм бик мавыктыргыч һәм күңелле узды. Катнашкан балалар бик канәгать калды.

***Виктория Нукина, X сыйныф укучысы***

**/Чал тарихта эзле без!/**

## “Ватан сагында” проекты



«Ватан сагында» проекты

(Бөек Ватан сугышыннан соң бүгенге көнгә чаклы армиядә хезмәт иткән авылдашлар турында мәгълүмат туплау)

| | |
|---|---|
| Исем, фамилия | |
| Туган елы | |
| Армиядә хезмәт иткән еллары | |
| Кайда хезмәт иткән (хәрби часть номеры) | |
| Гаскәр төре | |
| Хәрби званиесы | |
| Нинди хезмәт башкарган | |
| Өстәмә мәгълүмат (Армиядә төшкән фотолар, хәрби билет һәм башка документ копияләре булса яхшы) | |

Мәгълүматларны Түбән Майна урта мәктәбенә тапшырырга.

Электрон вариантларны түбәндәге адрес буенча җибәрергә.

e-mail: sch1644maina@mail.ru

Безнең мәктәптә яшь буынга хәрби-патриотик тәрбиягә бирү электән үк игътибар үзәгендә тора. “Ватанны саклаучылар көне” һәм Җиңү бәйрәмнәре зурлап үткәрелә, мәктәп музее даими рәвештә сугышчан экспонатларга баетыла. Алдагы елларда без Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлар буенча мәгълүмат базасын булдырган идек. Төрле чыганаклардан һәм беренче чиратта интернет сайтларыннан алынган документларга нигезләнеп, бу сугышта катнашкан 165 авылдашыбызга кагылышлы материаллар туплый алдык. Бу эш нәтиҗәсендә:

- моңарчы хәбәрсез югалган дип саналган 13 авылдашыбызның җирләнгән урыны ачыкланды;
- 35 авылдашның сугышка алыну һәм һәлак булу даталары тәгаенләштерелде;
- сугышта катнашкан 23 авылдашның исемнәре “Хәтер китабына” кертелмәве билгеле булды;
- 39 солдатның сугышчан юлы төгәл фактлар белән баетылды;
- авылдашларыбыз сугыш вакытында бүләкләнгән 52 орден һәм медаль турында белешмә алынды;
- хәрби званиелар буенча караганда, Түбән Майналылар арасында 6 офицер һәм 27 кече командирның булганлыгы расланды;
- 78 сугышчының фотосурәтләре табылды.

Хәзерге вакытка Бөек Ватан сугышында катнашкан 27 авылдашыбыз буенча исем-фамилияләреннән кала башка бернинди дә мәгълүмат юк.

Чыганаклар бик ярлы булуга карамастан, элегрәк булган сугышларда катнашкан авылдашлар турында да шактый күп мәгълүмат җыюга ирештек. Аерым алганда, Гражданнар сугышында катнашкан 60, Беренче дөнья сугышында булган 70 авылдашны ачыклый алдык. Болардан тыш, 1735-1870 нче еллар арасында рекрут буларак патша армиясенә алынган 35 авылдашның да исемнәре билгеле булды.

Инде менә Бөек Ватан сугышыннан соң армиядә хезмәт иткән авылдашлар буенча да эш башларга булдык. Моның өчен мәктәптә **“Ватан сагында”** дигән проект игълан ителде. Бу эшнең максаты – 1945 нче елдан алып, хәзерге чорга чаклы армиядә булган авылдашлар буенча мәгълүмат базасы булдыру. Әлеге категориягә 1927-1928 нче елларда туган ир-егетләрдән алып, соңгы елларда хезмәт итүчеләргә чаклы солдатлар керә.

Проектны тормышка ашыру мәктәп укучыларына йөкләнде. Эш махсус бланкны тутырып, солдатларның армиядә төшкән фотографияләре, хәрби билет һәм башка төрле документларның скан күчермәләрен алудан гыйбарәт. Читтәге авылдашларга проект турында социаль челтәрләр аша хәбәр ителде. Җыелган материалларны кәгазь яисә электрон вариантта мәктәпкә тапшырырга кирәк булачак.

“Ватан сагында” проекты буенча нәтиҗә ясау 23 нче февральгә планлаштырыла. Күбрәк материал җыючыларга мәктәп исеменнән истәлекле бүләкләр тапшырылачак.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***